**Әнәс Хәсәнов**

# Табигатькә тәрәзә

Парчалар

*Галина Панкратова* рәсемнәре

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2006

УДК 821.512.145-3
ББК 84 (2Рос=Тат)-4
Х91

**Хәсәнов Ә.Х.**

Табигатькә тәрәзә: Парчалар / Әнәс Хәсәнов. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006.— 24 б.

ISBN 5-298-03970-7

Әнәс Хәсәновның бу китабында хайваннар, кош-кортлар дөньясындагы кызыклы хәлләр тасвирлана.

ISBN 5-298-03970-7
© Татарстан китап нәшрияты, 2006
© Хәсәнов Ә.Х., 2006

## Кереш сүз

Яшь дус! Синең кулдагы кечкенә күләмле бу китапны мин бер газетада этләрнең ничек кешеләргә ярдәм итүе турында нәни генә мәкалә укыгач язарга булдым.

Англиядә яшәүче сукыр бер кеше урамга чыкканда үзен озатып йөрергә ике эт тоткан икән. Ул, тора-бара картаеп, чыгып йөри алмый башлый, этләрнең дә берсе сукырая. Ә икенчесе, сукыр иптәшенең муенчак очын авызына кабып, аны урамда һавада йөртеп керә икән. Менә бит нинди акыллы эт!

Ә авылда яшәүче бер танышым миңа мондый хәл сөйләде. Аларның Акбай исемле этләре бар икән. Менә шул эт көннәрнең берендә чыгып китә дә бер айлап югалып тора. Аннары ябык кына бер иптәшен ияртеп кайтып керә. Үзен гаепле санап, башын түбән иеп кенә йөри. Хуҗа аңа үпкәләми, ачуланмый, ашарына бирә. Ә Акбай, бераз ашагач, ризыкны иптәшенә калдыра. Аларның шулай бүлешеп ашаганын күргәч, хуҗа икенче этне дә үзенеке итә, чыгарып җибәрми. Тегесе дә аңа бик нык ияләшә, артыннан бер дә калмый йөри башлый.

Күзәтә белсәң, хайваннар, кош-кортлар дөньясына игътибарлы булсаң, бик кызыклы хәлләргә юлыгасың. Мин дә менә үз күзәтүләремнең кайберләрен сезнең белән уртаклашырга ниятләдем. Шуңа газеталарда очраткан кайбер башка күзәтүләрне дә өстәдем. Тирә-юньгә, табигатькә битараф булмасагыз, хайваннар дөньясы белән кызыксынсагыз, сез үзегез дә менә шундый китап яза аласыз. Әйдәгез, хәерле юлга!

## Акыллы этләр

Беркөнне, ишегалдында ял итеп утырганда, бик каты өргән эт тавышына игътибар иттем. Итәрлек тә шул. Нәни генә бер чәрелдек эт тавышы бөтен ишегалдын яңгырата, тавыш, ун катлы йортның биек стенасыннан кире кайтып, әллә кайларга тарала. Әллә берәрсе эт баласын кыерсытамы, дип уйлап куйдым. Алай дисәң, ул бит шыңшымый, зарланмый, ачуланып өрә.

Менә, ниһаять, бу тавыш иясе үзе дә куаклар арасыннан килеп чыкты. Шунда гына аның ник шулай борчылганын аңладым. Кечкенә эт бик зур бурзайга өрә икән. Аның корсак астына кереп, аяк асларында бутала, ярсып-ярсып, буылып-буылып өрә. Ә тегесе?

Этләр көлә белә дигәнне ишеткәнем бар иде. Аларның елмаюга охшаш кыяфәттәге фотосурәтләрен дә күргәнем бар. Тик менә бу зур этнең чын мәгънәсендә елмаеп баруын күргәч, гаҗәпкә калдым. Гаҗәпләнерсең дә шул! Теге кечкенә эт өрепме-өрә, атларга комачаулый, ә бу аңа һичбер илтифатсыз акрын гына атлый бирә. Әллә бар теге, әллә юк. Хәтта башын да бормый, койрыгын да селкетми. Ә үзе елмаеп бара. Вакланмый, янәсе. Мин, моңа гаҗәпләнеп, янымда утырган күршемә сүз куштым:

— Карале, дим, бу эт, елмаеп, тегесен мыскыл итеп бара бит! Бала-чага белән булышып тормыйм, ди, күрәсең.

Күршем дә моңа гаҗәпләнде.

— Хайваннар уйлый белми, диләр. Моны ничек аңлатасың?.. Беләләр, күрәсең,— дип куйды ул.

Кечкенә эт зур эт артыннан ләңгелдәп тротуарга кадәр барды, ә тегесе машиналар узып беткәнне көтте дә безнең йорт каршында гына үскән наратлар, чыршылар, өрәңгеләр арасына кереп китте.

## Урам аша чыкканда...

Оныгым белән Карл Маркс урамында трамвайдан төштек тә Кекин йортына таба юл тоттык. Абдулла Алиш исемендәге балалар сараена бию дәресенә баруыбыз иде. Кекин йортына җитеп, урамны чыгарга торганда, светофорда безгә яшел ут янды. Димәк, М.Горький урамы буйлап хәрәкәт итүче машиналар туктарга тиеш иде. Тик кая ул! Юл хәрәкәтен бозу хәзер берни түгел бит.

Шул мизгелдә без оныгым белән бер эткә игътибар иттек. Ул гап-гади, токымсыз гына эт иде. Урам уртасына чыккан да тәртип бозып, кызыл утка карамастан хәрәкәтен дәвам итүче машиналарга ташлана, өрә. Аннары икенчесе артыннан элдертә.

Менә, ниһаять, тәртип саклаучы машиналар светофор янында туктап калды. Эт тынычланды булса кирәк, борылып безнең янда басып торган бер 8—9 яшьлек малай янына килде дә, аның йөзенә карап, бер-ике генә өреп куйды. Аннары алар икенче якка чыгып киттеләр, без дә оныгым белән юлыбызны дәвам иттек. Урам уртасына җитәрәк эт машиналар алдында туктап калды, теге малайның юл аша чыгып беткәнен көтте. Аннары уйнаклап аңа иярде.

Мин, аның машиналарга ташланып өреп, чабып йөргәнен күргәч: «Менә тинтәк, машина астына эләгә бит инде»,— дип уйлап өлгергән идем. Тик ялгышканымны шунда гына аңладым. Ул бит акыллы, теге малайны — хуҗасын саклаган, аңа юл бирмәгән өчен машиналарга ачуланып, чәбәләнеп йөргән икән. Хуҗасына хәвефле урам аша чыгарга булышкан лабаса.

Менә сиңа тинтәк! Шуңа төшенгәч, миңа уңайсыз булып китте. Әйе, хайваннар уйлый беләләрдер, күрәсең. Һәрхәлдә, алар кешенең якын дусты була беләләр. Менә шулай моңа тагын бер кат инандым.

## Бобик Голливуд чибәрләре кебек елмая

Биологлар, җитди төстә, этләр көлә белә, тик без аларны һәрвакыт аңламыйбыз гына, дип раслыйлар.

АКШтагы хайваннарны яклау үзәкләренең берсендә эшләүче фәнни хезмәткәр Патрисия Симонет, этләр мәзәк уйлап чыгарырга һәм шаярырга сәләтле, дип раслый.

Ул озак еллар буена хуҗасыз калган этләрне асрый торган йортта эшли икән. Хайваннарның үз-үзләрен тоту тәртибен өйрәнгәндә, ул йорт этләренең хуҗаларына ияреп һавага чыгарга хәзерләнгәндәге авазларын аудиотасмага язып алган, һәм язманы үз тәрбиясендәге этләргә тыңлаткан.

— Алар хәтта ашауларыннан туктадылар,— дип сөйли Патрисия.— Аннары мин тавышны көчәйтә төштем. Нәтиҗә шаккатырды. Этләр, йөгереп килеп, яныма җыелдылар. Берәр минуттан соң алар йорт этләренә җавап биргәндәй өрә башладылар һәм тегеләрнең тавышын төгәл кабатладылар.

Икенче көнне язманы радио аша яңгыраттык, һәм язмадагы тавышка хуҗасыз калган бездәге этләр дә шатлыклы чиный башладылар. Тикшерүләр әнә шундый шатлыклы авазларның боек этләрнең күңелен күтәргәнен, ә борчылганнарны, ярсыганнарны тынычландырганын белдек.

Һавага чыгар алдыннан этләр авазын кешеләрнең шатлыклы көлүе белән чагыштырып була. Хәтта алар яңгыраулары белән дә шактый ук охшаш. Мин этләр янында үзем дә көлеп карарга булдым. Моны мин сиземләүгә таянып кына, ләкин берниндн ачык нәтиҗә көтмичә генә эшләгән идем,— ди Патрисия.— Һәм кабат гаҗәпләндем: этләр бер генә минутка тын калдылар, ә аннары минем көлү тавышыма охшаш авазлар чыгара башладылар. Күңелгә «алар моны миңа ияреп кенәме, әллә аңлы төстә эшләделәрме икән» дигән уй килде.

Тиздән фәнни хезмәткәр бу сорауга да җавап ала. Бер- көнне аның кәефсез чагы була. Шунда, моны сизгәндәй, этләрнең берсе Патрисиянең көлгән тавышын «хәтеренә төшерергә» теле.

— Минем күптәнге дустым — Джеб дигән тугры эт — күземә карап көлә башлады,— ди Патрисия.— Бу шаккатыргыч хәл иде. Мин дә борчуларымны шунда ук онытып көлә башладым. Ә бер минуттан безнең тирәдәге башка этләрнең дә Джеб белән миңа кушылып көлгәнен аңладым.

Хәзер инде асрама этләр йортына радиодинамиклар куела һәм этләр «көлүе» даими яңгырап тора. Биредәге хезмәткәрләр, моны борчулы этләрне тынычландырырга һәм тиешле тәртип урнаштыруга булыша, диләр.

— Этләр белән менә шулай ярты ел эшләгәч, мин аларның кайчан, ничек «көлүләре» турында мөһим нәтиҗәләр ясый алдым,— дип дәвам итә Патрисия.— Дүрт аяклы дуслар менә шулай тиздән һавага чыгу шатлыгын яисә нинди булса да башка шатлык көтүләрен чагылдырып кына калмыйлар. Алар бер-берсеннән, ә бәлкем, безнең өстән дә шаярталардыр әле. Мәсәлән, бермәлне шундый бер вакыйга булды. Этләрнең берсе, азык савытына йөгереп килгәндә, башы белән рәшәткәгә килеп бәрелде. Моны күреп торган этләр комсыз туганыннан шунда ук «көлеп» җибәрделәр. Ә бу хәлне күрмәгәннәре, башкалардан кызыклы хәбәр алып, күрәсең, соңрак «көлә» башладылар.

— Мин инде хайваннарның гадәтләрен, аларның үз-үзләрен тотышларын утыз ел буена өйрәнәм һәм безнең дүрт аяклы дусларыбыз без исәпләгәнгә караганда бик күпкә артыграк сиземлиләр һәм аңлыйлар дип саныйм,— ди профессор Ольга Силаева да.— Күпьеллык тикшеренүләр этләрнең иң югары хисләргә — тугрылыкка, кызгануга, яратырга сәләтле икәнен раслый. Ә менә көнләшү, түбәнлек кебек тойгыларны алар белми. Этләр, һичшиксез, юмор хисенә дә ия. Кайбер этләрнең кеше теле белән сөйләшергә маташуы да инде билгеле нәрсә. Бу безнең телгә ияреpгә тырышу түгел, ә кешеләр белән уртак тел табарга омтылыш юлы, күрәсең.

Күзәтергә яратсаң, хайваннар тормышында әллә нинди кызыклы хәлләр күрергә була. Виктор исемле бер кеше менә нинди кызыклы вакыйга турында яза.

«Беркөнне бик иртән ачык тәрәзәдән мин ишегалдыннан килгән кыштырдаган тавышка игътибар иттем,— ди ул.— Гадәттә андый тавыш ишегалды себерүчеләр эшләгәндә чыга: шыш-шыш-шыш. Тавыш йокымны качырды, тәрәзә янына барып, урамга карамыйча булмады. Ә анда урам этләре шаяра икән. Ничек дисезме? Чүп савытлары яныннан шактый зур, калын целлофан кисәге тапканнар да шуның белән уйнапмы-уйныйлар! Берсе дүрт аягы белән дә целлофанга менеп баскан да рәхәтлектән койрыгын пропеллер сыман уйнатып тора. Икенчесе, тешләре белән эләктереп, целлофанны сөйрәп йөри. Яннарында тагын ике эт, түземсезләнеп, кыбырсып, кайчан чират җитә дигәндәй өргәләп алалар. Ә тегеләр ун метрлап барган урыннарын алышалар, целлофанга инде әле генә тартып йөргәне менеп баса, тегесе тартып йөри. Урам этләре тормышында да шатлыклы вакытлар була икән ләбаса».

Соңгы еллардагы ачышлар галимнәрне безнең дүрт аяклы дусларыбызның гадәтләре, үз-үзләрен тоту серләре турында торган саен ешрак уйландыра, хайваннар физиологиясе фәненең күп кенә битләрен яңадан карап чыгарга мәҗбүр итә.

### Зирәк песи

Безнең өйдә көрән төстә, чисталыкны бик ярата торган песи яши. Аны әле бик кечкенә чагында ук оныгыбыз Динә урамнан табып кайтты. Исемен дә ул кушты — Дана.

Песиебез туктаусыз чистарына, гәүдәсен, битләрен, хәтта колак эчләрен дә тырыша-тырыша юа. Хаҗәтен туалетка кереп үти, аннары бик озак итеп аны күмә. Мин аның хаҗәтен туалеттан тыш башка урында үтәгән очракны белмим.

Буш чагымда мин Дананы күзәтергә яратам. Бүлмә ишеге каты ябылмаганда, ул аны аяклары белән ачып керә, ачып чыга. Катырак ябылган чакта, идәнгә ята да ишек белән идән арасына аягын тыгып ачарга тырыша. Булдыра алмаса, каршыңа килеп ярдәм сорый. Күзең йомык икәнне күрсә, борчымый, торып йөри башлаганыңны көтә.

Квартирага ремонт ясаганда, тәрәзәдән алынган пәрдә бераз эленми торды. Данага рәхәт, тәрәзә төбенә сикереп менә дә югарыдан урамдагы хәлләрне күзәтә. Менә, ниһаять, тәрәзәгә стенадан стенага, түшәмнән идәнгә кадәр сузылган пәрдә эленде. Данага тәрәзә төбенә сикереп менү мөмкин булмый башлады. Хәзер нишләр икән?

Җаен тапты бит. Башта агач караватбашына сикерә, аннан тәрәзә янына ук килә дә пәрдәне йә аягы, йә башы белән этеп сикереп менә. Төшкәндә дә шулай. Тора-бара ул болай йөрүдән туйды, күрәсең. Нишләде дисезме? Тагын бер җай тапты. Хәзер ул караватбашына менеп тормый, тәрәзә төбенә идәннән генә сикерә. Ә башта, юлында комачаулап торган пәрдәне башы белән этеп, ике арага керә. Аннан инде сикерәсе генә кала. Аңа акыллы песи дими ни дисең инде!

* * *

Кеше этне үзенә әкренләп ияләштергән. Ә мәчене махсус ияләштермәгән, мәче үзе ияләшкән. Борынгы Мисырда мәчеләр кешеләр тирәсенә елышканнар, ә мисырлылар аларны артык үз итмәгәннәр. Ләкин тора-бара хәл үзгәргән. Амбарлардагы икмәккә тычканнар бик зур зыян салганны белгәч, мисырлылар моннан мәче асрап кына котылып буласына төшенгәннәр. Хәтта бер мәченең, тычкан тотып, хәзерге исәп белән 2,5 тонна икмәк саклап кала алганын исәпләп чыгарганнар.

Мисыр патшасы — фиргавен — бу турыда белгәч, мәчеләрне сакларга, ә крестьяннарга торараклары янында мәчеләргә сөтле чүлмәкләр куярга боерган. Тора-бара мәче культы Борынгы Мисырда бик югары дәрәҗәгә күтәрелгән. Мәчене үтергән кешене үлем җәзасына тартканнар. Мәчеләргә зур-зур зиннәтле сарайлар төзегәннәр, аларда меңәр-меңәр мәче яшәгән. Фиргавеннәрнең яраткан мәчеләрен, үлгәч, бәлзәмләп, алтын саркофагларга салып, хуҗалары янына күмгәннәр.

* * *

Урта гасырда яшәгән инглизләрнең дә мәчеләргә мөнәсәбәте бик кызыклы. Король Ричард I идарә иткән заманда Лондонда күселәр, тычканнар бик азган, шәһәрдәге барлык азык-төлек запасын бозып бетергәннәр. Шәһәрдә коточкыч ачлык һәм авырулар башланган. Шул чакта кешеләр мәчеләрне искә төшергәннәр. Ричард I әмере белән тирә-юньдәге урманнардан йөзләрчә мәче тотылган һәм кимерүчеләр яшәгән урыннарга, идән асларына җибәрелгән. Тиздән мәчеләр тычканнарны, күселәрне кырып бетергәннәр. Авызына күсе капкан мәчене күргән шәһәр кешеләре аны баш киемнәрен салып зурлаганнар. Мәче бәясе берничә алтын тәңкәгә җиткән.

Соңрак инглиз диңгезчеләре дә, ерак илләргә барганда, корабль трюмнарында мәчеләр асраганнар. Мәче корабль командасы әгъзасы булып саналган. Судно журналында диңгезчеләр исемлегенә мәчеләр исеме дә кертелгән һәм аның янына «Кайда тели, шунда йөрергә хаклы!» дигән искәрмә дә язып куелган.

## Аучы чыпчык

Чыпчыкны без аны кошка да санамыйбыз бугай. Очамы — оча, черкелдиме — черкелди. Әллә бар, әллә юк. Тик менә шуны гына күз алдына китереп карагыз әле: кинәт кенә барча чыпчык юкка чыкты ди. Тормышыбыз яме ничек кимер иде.

Мин бала чакта чыпчыклар бик сак иде. Үз яннарына кешене 5 — 6 метрдан якынрак җибәрмиләр иде. Ә хәзер шәһәр җирендә аяк астына ук керәләр. Көнбагыш белән сыйласаң, кулың тирәсендә үк бөтереләләр. Замана кошларны да үзгәртә, күрәсең.

Буш вакытымда мин аларны күзәтергә яратам. Аларның үз-үзләрен тотышыннан тәҗрибәлеме, юкмы икәнлеген дә белеп була. Томшыкларына игътибар итсәң, бигрәк тә. Томшыклары агарган икән, димәк, олы яшьтәге, тәҗрибәле чыпчык, бала түгел. Әнә берсе биек үлән арасында очып йөргән нәни генә күбәләкне аулый. Күбәләк тоттырмый, юнәлешен үзгәртеп, әле бер, әле икенче якка ташлана. Яшисе килә. Ә чыпчык аны йә узып китә, йә талпынып өлгерә алмый, артта кала.

Күбәләк артыннан үлән арасына керергә никтер кыймый, көтә. Тегесе күтәрелүгә, тагын һөҗүм итә, тик берни барып чыкмый, күбәләк,
үртәгәндәй, куе әрекмәннәр
арасына кереп югала.

## Чыпчык туңдырма ашый

Троллейбус тукталышында басып торам. Үз маршрутларын көтеп алган кызлар, чыр-чу килеп, троллейбус ишегенә кереп киттеләр. Берсе ашап бетермәгән туңдырма кисәген чүп савытына ташлады, эрегән туңдырма тамчысы асфальтка да чәчрәп калды. Ул тирәдә чыпчыклар бөтерелә. Берсе тамчыны татып карады да тиз-тиз генә эчеп бетерде. Аннары, очып, чүп савыты кырыена кучте. Тирә-якка күз ташлагач, аның эченә үк төшеп китте. Бер-ике секундтан пырылдап очып чыкты, янә кырыйга кунды. Ул-бу юклыгын абайлагач, янә төшеп китте. Бу бик күп мәртәбәләр шулай кабатланды. Башкалары урна тирәсендә чүпләнеп йөргәндә, бу үзенә бер бәйрәм ясады.

Мин уйлап куйдым: акыллы чыпчык. Сагая да белә, тамагын да туйдыра.

## Чыпчыклар бәхәсе

Җәйге эссе көннәрнең берсендә урам буйлап бара идем, кинәт юл өстендә җиде-сигез адым алдарак ике чыпчыкка күзем төште. Алар икесе дә чәрелди, тик берсе, канатларын җәеп, асфальтка чалкан яткан, икенчесе аның өстенә кунып, дөньясын онытып һөҗүм итә, тегенең ачык авызын чукый. Белмим, араларында нинди бәхәс чыккандыр. Мин яннарына килеп җиткәнне дә соң гына абайладылар. Усалы пырылдап агач ботагына барып кунды. Асфальтта ятканы, әйләнеп, аягына басты. Мин китә башлагач, чыркылдап, ун-унбиш адым миңа ияреп килде.

Белмим, бәладән коткаруыма рәхмәте булдымы, әллә теге усалдан яклавымны телəдеме. Усалы безне ботактан ботакка, агачтан агачка күчеп күзәтеп барды, мин барында кабат һөҗүм итәргә базмадымы, әллә башка сәбәп булдымы. Мин ни булыр икән дип туктап көтә башладым. Сугыш чукмарының түземлеге минекеннән әзрәк икән, каты чыркылдап читкә очып китте. Буй биргәне дә бераздан койма ярыгы аша шыпырт кына яфраклар арасына чумды.

## «Морж» чыпчык

Черек күл кырыендагы урам буйлап атлыйм. Кышның җылы, кояшлы көне. Биек-биек кар көртләре чип-чиста, монда машиналар сирәк йөри, тыныч. Кояш төшкән урыннарда боз сөңгеләреннән тамчылар тама. Кинәт чыпчыклар чыркылдаган тавышны ишетеп туктап калам. Әнә алар өрәңге ботагына тезелешеп утырганнар да чыр-чу киләләр. Ник шулай гауга күтәргәннәр соң әле бу әрсезләр? Ни булган? Мәче күргәннәрме әллә?

Түбәләрдән яңгыр суы агар өчен эшләнгән торбага күзем төшкән иде, гаҗәпләнүдән телемне шартлатып куйдым. Торбадан берән-сәрән генә кайдадыр югарыда эрегән кар суы тамып тора. Шул тамчылардан ясалган нәни генә чокырга бер чыпчык кереп утырган да су коена. Кыш көне! Томшыгына, канатларының төсенә караганда әле яшь күренә. Менә сиңа «морж» чыпчык! Каурыйларын торгызган. Үз телендә бик җанланып нидер сөйли, өстенә салкын су тамчысы тамган саен чыркылдый, ә читкә китәргә, башкаларга урын бирергә исәбендә дә юк. Аңа карап бүтәннәре ду килә. «Юләр» йә «вәт батыр бу!» диюләреме икән?

Минем янга тагын бер-ике кеше килеп туктады, елмаешып «морж»ның су коенганын күзәтәбез. Ә аның исе дә китми! Үз эшен белә, рәхәтләнә. Аннары туйды бугай, чокырчыктан чыкты да очып китеп барды.

Бу батыр кошчык минем күңелгә мәңгегә уелып калды. Чыпчык күргән саен, шул «морж» искә төшә.

## Акыллы ала карга

Ала каргаларны акыллы дип мактаганнарын ишеткәнем бар иде. Аларның, күмәкләшеп, сөяк кимереп яткан этнең азыгын талап алып китүләре хакында да укыганым бар. Ләкин менә ипи катысын суда җебетеп ашаулары турында укыганым да, ишеткәнем дә юк иде.

Бакчадагы яшелчәләргә салкын су сибәргә ярамаганга, без бакчабызда мичкәгә су тутырып куябыз, җылынгач кына сибәбез. Беркөнне иртән, су җылынгандыр инде дип мичкә янына килсәм, кичтән тутырып калдырган суда шактый зур күмәч кисәкләре күреп исем китте. Суга кем салган аларны? Өйдәгеләрдән дә сорашып карадым, юк, без салмадык, диләр. Күмәч кисәкләрен алып бер читкә куйдым, суны сибеп бетергәч, мичкәгә янә су тутырдым. Иртән уянып бакчага чыксам, мичкә янында күмәч кабып торган ала карганы шәйләдем. Мин килә башлагач, ул, авызындагы телемен суга ташлап, качу ягын карады. Мичкәдә тагын берничә кисәк күмәч йөзеп йөри иде. Димәк, аларны ала карга китереп ташлый икән. Ни өчен?

Уйлана торгач, мин моның сәбәбенә төшендем бит, әй. Ул елны җәй бик коры килде. Үләннәр корып бетте. Бакчабыздан читтәрәк чүплектә җирдә азык-төлек калдыклары да күп очрый иде. Кояшта алар катыланып кибә. Ала карга аларны, су тулы мичкәгә алып килеп, җебетеп ашый икән ләбаса. Мин, моны тәгаенләр өчен, теге мичкәдә суны яртылаш кына калдырдым. Кунар урыны булмагач, карга анда төшә алмас, дип уйлыйм.

Чыннан да, карга анда төшмәгән, суы тулы икенче мичкәгә ипи катылары, хәтта кибеп, корып беткән балык башлары китереп салган, сыйланган. Суны пычратканга ачуым килсә дә, мин бу кошның акылына сокландым. Бик иртә торган көннәрдә аның мичкә тирәсендә кайнашып, тамак хәстәрен кайгыртып йөрүенә гаҗәпләндем, сай гына тимер тәлинкәгә су салып, җиргә куя башладым. Ала карга, дус-ишләрен дә ияртеп, бәйрәм итәргә маһирланды. Бакча җиләге өлгерә башлагач, җитезлекләре тагын да артты.

Юк, мин әйтәм, болай ярамый икән сезнең белән. Җиләкләрне бозып бетерәсез. Җиләк түтәлләренә полиэтилен тасмалар таккан баулар суздым, карачкылар да ясап куйдым. Беркөнне бик иртән кошлар тавышына уянып чыксам, исем китте. Хет көл, хет ела. Карачкыларымның берсенә ала каргалар, икенчесенә саесканнар менеп кунаклаган. Шау-гөр килеп нәрсәдер бүлешәләр. Бигрәк тә саесканнар чәрелди. Белмим, миннән көлүләре идеме, әллә түтәл бүлешүләре идеме?!

## ЭЧТӘЛЕК

Кереш сүз
Акыллы этләр
Урам аша чыкканда...
Бобик Голливуд чибәрләре кебек елмая
Зирәк песи
Аучы чыпчык
Чыпчык туңдырма ашый
Чыпчыклар бәхәсе
«Морж» чыпчык
Акыллы ала карга

Литературно-художественное издание

***Хасанов*** *Анас Хасанович*

**ОКНО В ПРИРОДУ**

*Зарисовки*

Казань. Татарское книжное издательство. 2006
На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

***Хәсәнов*** *Әнәс Хәсән улы*

**ТАБИГАТЬКӘ ТӘРӘЗӘ**

*Парчалар*

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *А.С.Газизҗанова*
Корректоры *Г.Г.Гарифуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 19.09.2006. Форматы 70х100$^{1}$/16.
Офсет басма. Шартлы басма табагы 1,95. Шартлы буяу-оттиск 9,10.
Нәшер-хисап табагы 2,33. Тиражы 3000. Заказ З-808.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://www.tatarstan.ru/books/E-mail: tki@books.kazan.ru.**
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ. 420066.
Казан, Декабристлар урамы, 2.